СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.06.2025 № 59/1

На № ______ от ____________

# КАРАР

**«Тукай муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2021 елның 14 декабрендәге 15/7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль закон, 2023 елның 18 мартындагы 71-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районы уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Тукай муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2021 елның 14 декабрендәге 15/7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 өлешнең 3.5 пункты 3.5.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Профилактик визит инспектор тарафыннан контрольдәге затның эшчәнлек алып бару урыны буенча профилактик әңгәмә формасында яисә видео-конференц-элемтәдән яки «Инспектор» мобиль кушымтасын файдалану юлы белән үткәрелә.

Профилактик визит барышында контрольдәге затка үз эшчәнлегенә яисә аңа караган контроль объектларына куела торган мәҗбүри таләпләр, аларның хәвеф критерийларына туры килүе, хәвеф категориясен киметүнең тәкъдим ителгән ысуллары, төрләре, эчтәлеге һәм контроль объектына карата аны тиешле хәвеф категориясенә кертүдән чыгып үткәрелә торган чараларның интенсивлыгы турында хәбәр ителә, ә инспектор контроль объекты белән танышу, контроль объектларын хәвеф категорияләренә кертү өчен кирәкле белешмәләр җыю һәм контрольдәге затның мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсен бәяли.

Профилактик визит контроль (күзәтчелек) органы инициативасы буенча (мәҗбүри профилактик визит) яки контрольдәге зат инициативасы буенча үткәрелә.

Профилактик визит үткәрү йомгаклары буенча контроль объектына «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»

2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы 6 һәм 7 өлешләре нигезендә мәҗбүри таләпләрне үтәү дәрәҗәсенә гавами бәя бирелергә мөмкин.»;

1.2. 1 өлешнең 1.2 пунктына түбәндәге пунктчаны өстәргә:

«12) йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын куркынычсыз эксплуатацияләүгә һәм техник хезмәт күрсәтүгә карата таләпләр, шулай ук күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәткә караган вентиляция һәм төтен каналларын карап тотуга карата таләпләр.».

1.3. 1 өлешнең 1.6 пункты 2 пунктчасында «1-11» саннарын «1-12» саннарына алыштырырга;

1.4. 1 өлешнең 1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль торак күзәтчелеге предметы булып юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр һәм гражданнар (алга таба – контрольдәге затлар) тарафыннан торак законнарында, энергия саклау һәм энергетик нәтиҗәлелекне арттыру турында законнарда, Россия Федерациясендә торак фондына карата, муниципаль торак фондыннан тыш, газ белән тәэмин итү турында законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү тора:».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), районның рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров